T. A. S. S. Ç. Qazan LENIN isem. ÖLKӘ MASSA KITAPXANӘSE TGP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ ТАССР г. Казань
Уг. К№27

ЯКШӘМБЕ
17 МАРТ
1940 ел
№ 64 (5864)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Авылда культура-масса эшләрен яхшыртырга

Бөек большевиклар партиясенең һәм иптәш Сталинның туры-дан-туры җитәкчелегендә авылда социалистик культура гаять зур уңышларга ирешге. Иске, караңгы һәм пычрак авыл юк инде. Аның урнына яңа авыл—социалистик авыл төзелде. Авылларда йөз меңнәрчә яңа, совет интеллигенциясе—укытучылар, агрономнар, клуб һәм уку өе мөдирләре, врачлар армиясе туды. Алар колхозчы крестьяннәрнең киң массасына белем, культура алып киләләр. Безнең орденлы республикабызда гына да 3.541 мәктәп, 1.907 көтепханә, 2.989 клуб һәм уку өйләре бар.

Ленин—Сталин партиясенең тарихи XVIII нче съезды Сталинчыл өченче бишьеллык планның төп политик бурычы итеп хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү бурычын куйды. Бу бөек бурычны тормышка тулысынча ашыруда хезмәт ияләрен культура ягыннан тәрбияләү эше хәл иткеч чара булып тора. „Хәзер безнең дәүләтнең ил эчендә төп бурычы — хуҗалык-оештыру һәм культура-тәрбия буенча тыныч эштән гыйбарәт" (Сталин).

Республикабызның күп кенә партия, совет оешмалары һәм культура учреждениеләре моны бик яхшы аңлыйлар һәм үзләренең барлык эшләрен тарихи съезд тарафыннан куелган бурычларны тулысынча үтәүгә юнәлдерәләр. Алар клубларның, уку өйләренең, кызыл почмакларның эшләрен системалы рәвештә тикшереп, аларга конкрет ярдәм күрсәтәләр.

Колхозлардагы, совхозлардагы клублар, уку өйләре—алар, социалистик авылның культура учаклары. Алар гаять зур политик эш алып баралар. Авыл хезмәт ияләренең культура дәрәҗәләрен күтәрү буенча зур эш башкаралар.

Бондюг районының Турай һәм Песәй авылларындагы клублар соңгы вакытларда үзләренең эшләрен шактый яхшыртуга ирешләр. Клублар чиста, җылы һәм якты. Кирәкле мебельләр белән тәэмин ителгәннәр. Колхозчылар бирегә килеп, яңа газета, журналларны укый алалар. Песәй авылы клубында ПВХО һәм ГСО түгәрәкләре эшлиләр һәм шушы көннәрдә оборона ярышлары үткәрелде.

Кильдеево авылы клубы (Югары Ослан районы) янында драмтүгәрәк, Осоавиахим, МОПР оешмалары һәм сугышчан алласызлар ячейкасы оештырылган. Алар яхшы гына эшләп киләләр. Клуб мөдире иптәш Молгачев агитация эшен яхшы оештыра белү нәтиҗәсендә, социалистик ярышны киң җәелдерүгә, хезмәт дисциплинасын күтәрүгә ирешге. Клуб янында чыгарыла торган стена газетасы алдынгыларның тәҗрибәләрен яктырта, югары уңыш өчен көрәшә.

Ләкин, кайбер урыннарда, партия, совет һәм комсомол оешмалары авыл халкын коммунистик рухта тәрбияләүдә культура-масса эшләренең никадәр зур роль уйнаганлыкларын аңлап җиткермәгәннәр әле. Алексеевский районы үзәгендәге уку өенең ташландык хәлдә калдырылуын тагын нәрсә белән аңлатырга мөмкин соң? Биредә уку өе тәмәке тарту, шаяру урнына әвереләдерелгән. Шунысы гаҗәп: уку өе ВЛКСМ райкомы белән янәшә генә булуга да карамастан, уку өенең эшенә комсомол җитәкчелеге күренми.

Яки икенче факт. Куйбышев районы үзәгендәге клубта пычраклык хөкем сөрә. Клубның һәм көтепханәнең тәрәзәләре ватык, аларга якмыйлар. Шуңа күрә дә клубта эчүчелек, хулиганлык фактлары еш кына кабатланалар. Район җитәкчеләре клубның эшен яхшырту чараларын күрү урнына „утын юк" дип клубны бөтенләй ябып куюдан башка чара таба алмаганнар.

Культура учреждениеләренә мондый карашлы „җитәкчеләр" бездә аз, билгеле. Ләкин алар бар әле һәм алар безнең гомуми эшкә комачаулыйлар. Партиянең район комитетлары һәм район советларының башкарма комитетлары авыллардагы культура учреждениеләренең эшләрен яхшырту өчен кискен чаралар күрергә тиешләр.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче большевистик язы якынлаша. Язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрү эшендә культура-масса эшләре гаять зур политик әһәмияткә ия булып торалар. Язгы чәчүгә хәзерлек эшенең торышы белән колхозчыларның киң массасын системалы рәвештә таныштырып бару, алар арасында беседалар, газета-журналлар укуны оештыру, стена газетасын һәм бригада газеталарын чыгарып, аларда эш тәҗрибәләрен уртаклашуны яктырту—авыл культура учреждениеләре алдында торган төп бурычларның кайберләре әнә шулар. Клуб, уку өе һәм кызыл почмак үзләренең тәрбияләү һәм барлык массовый эшләрен колхоз, совхоз, МТС лар алдында торган политик һәм хуҗалык бурычларны уңышлы хәл итүгә юнәлдерергә тиеш.

Алда торган политик бурычларны уңышлы хәл итү өчен культура учреждениеләренең практик эштә сыналган, халыкка чынбарлыкны дөрес итеп аңлатып бирә торган кадрлары булырга тиеш. Алар үз тирәләренә актив тупларга тиешләр. Бу кадрларны, активны тупламый торып, культура-масса эшләрен киң җәелдерү турында сүз булуы мөмкин түгел. Безнең күп кенә клуб, уку өе мөдирләре, моны аңламыйча, барлык эшне үзләре генә алып барырга омтылалар. Нәтиҗәдә, үз теләкләренә ирешә алмыйлар. Хәзерге вакытта авылның культура көче зур. Укытучылар, агрономнар, врачлар, комбайнчылар, тракторчылар һәм башкалар культура-масса эшләрен яхшы һәм тулы эчтәлекле итеп оештыруда партия, совет оешмаларына тулы булышлык күрсәтә алалар. Бары тик аларны клуб, уку өйләре тирәсенә тупларга һәм алардан урынлы файдаланырга кирәк.

Клуб, уку өе, кызыл почмак мөдирләре һәм укытучылар—авылның алдынгы кешеләре. Алар хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә партиябезнең беренче ярдәмчеләре. Партия һәм Совет хөкүмәте бу иптәшләргә гаять зур ышанычлык күрсәтә. Клуб, уку өе мөдирләре һәм укытучылар бу ышанычны культура фронтында тагын да яңа уңышларга ирешеп акларга тиешләр.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

ТРАКТОРЧЫЛАР, ЯҢАДАН МТС та ЭШЛӘРГӘ КАЙТЫГЫЗ!

Совет дәүләте МТС работникларына турында көн саен зур кайгыртучанлык күрсәтә, аларның культура һәм көнкүреш дәрәҗәләрен яхшырту буенча барлык чараларны күрә. Барлык тракторчылар өчен хезмәт көннәренә натуралата түләүнең гарантияләнгән минимумы билгеләнгән, тракторчыларның хезмәтләренә акчалата түләү расходларын дәүләт үз исәбенә алды һәм ягулыкка экономия ясаган өчен премия бирү системасы кертелде. Комбайнчыларга да күп кенә льготалар бирелә. Авыл хуҗалыгының бай техникасын тулы һәм бик яхшы итеп файдалану өчен безгә барлык шартлар тудырылды.

Ләкин, шуңа да карамастан, безнең МТС та, күп кенә башка МТС ларда кебек ук, тракторчылар кадрлары житешми. Күп кенә тракторчылар төрле сәбәпләр белән узган елларда МТС тан киттеләр һәм хәзер алар үз специальностьлары буенча эшләмиләр. Тракторчылар җитешмәвен, бөтен тракторчыларның быел хәзерләнә торган яңа кадрлары исәбенә генә каплау һич тә мөмкин түгел.

Менә шуны күреп без, элекке тракторчыларны һәм комбайнчыларны яңадан МТС ка кайтару чарасын күрә башладык. Комбайнчы Хабибрахман иптәш Саттаров күптән түгел генә МТС ка килгән иде. Узган елны ул, семья мәсьәләсе буенча, МТС тан китте һәм бер ел буена „Трактор" колхозында эшләде. Хәзер ул яңадан комбайнда эшләргә кайтырга булды. Иптәш Саттаров белән сөйләшкәндә, ул болай диде:

— Минем укыту өчен дәүләт бик күп средство тотты. МТС тан китеп мин ялгышлык эшләдем. Миңа яңадан комбайн штурвалы янына басарга мөмкинлек бирүегезне сорыйм.

Хәзер иптәш Саттаров МТС мастерскоенда стахановчы булып эшли, ул машинасына ремонт ясый.

Бригадир ярдәмчеләре И. Шәйхетдинов һәм И. Гатауллин иптәшләр дә МТС та эшләргә кайталар. Хәзер алар яңадан тракторда эшләргә карар бирделәр.

Бездә мондый тракторчылар аз түгел. Без, теге яки бу сәбәп белән МТС тан киткән барлык тракторчыларны һәм комбайнчыларны язгы чәчү башланганчыга кадәр яңадан МТС ка кайтаруны бурыч итеп куйдык. Моның өчен безнең МТС ның элекке кадрлары арасында масса-аңлату эшен киң җәелдерәбез, тракторчыларга культура һәм көнкүреш шартларын яхшырту турында конкрет чаралар күрәбез. Шушы юл белән без кимчелекне кадрларыбызны МТС ка даими рәвештә беркетә алачагыбызга һич шикләнмибез.

Тракторчы иптәшләр! МТС ларда һәм совхозларда эшләргә кайтыгыз! Колхоз кырларында стахановчылар булып эшләп, колхоз строеның җиңүләрен тагын да арттырыгыз!

Ф. Габдеев.
Этнә МТС ның өлкән агрономы.

Социалистик ярыш ярдәм итте

Мамадыш районының „Игенче" һәм „Хәсәнша" колхозлары язгы чәчүгә яхшы хәзерләну өчен үзара социалистик ярышка чыкканнар иде. Ярыш зур ярдәм итте.

Соңгы көннәрдә бу колхозларның язгы чәчүгә хәзерлекләре тикшерелде. Тикшерү „Игенче" колхозының язгы чәчүгә тулысынча хәзер булуын, ярыш договорының барлык пунктларын да тулысынча үтәвен күрсәтте. Язгы чәчү вактында кирәкле барлык машиналарга ремонт ясау төгәлләнгән. Ремонттан чыккан машиналар комиссия тарафыннан акт буенча кабул ителгән һәм бригадирларга да акт буенча тапшырылган. Чәчү орлыкларының сыйфаты яхшы.

Масса-аңлату эшләре дә кулышы районыдагы күп кенә колхозларга үрнәк булырлык. Колхоз правлениесе янында һәм бригадаларда системалы рәвештә стена газеталары чыгарыла. Бригадалар арасындагы ярыш договорларының үтәлеше 15 көн саен тикшерелә һәм тикшерү нәтиҗәләре шушы газеталарда яктыртыла.

Атлар көр. Алар аерым колхозчыларга беркетелгәннәр.

Бу колхоз узган ел бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 105 пот иген уңыш алган иде. Быел колхозчылар һәр гектардан 120 пот уңыш алу өчен көрәшәләр.

Район колхозларында орлык белән үзара ярдәмләшү киң колач алды. Теләче авылы колхозчыларының инициативасына беренче буларак, „Хәсәнша" һәм „Игенче" колхозчылары кушылдылар. „Хәсәнша" колхозы членнары үзләренең гомуми җыелышларында „Югары Яке" колхозына 455 центнер орлык бирергә карар чыгардылар. Колхозчылар үзләренең хезмәт көннәренә алган ашлыктан да 95 центнер орлык бирделәр.

Г. Ногманов.

КОЛХОЗЛАР БЕР-БЕРСЕНӘ БУЛЫШАЛАР

МӨСЛИМ, (Телефон буенча). Районның кайбер колхозларында орлык, солы, вика һәм бәрәңге орлыклары җитешми. Ләкин бу орлыкларны колхозлар арасында ярдәмләшү тәртибендә районның үзендә тулысынча табарга мөмкин. Моңа без бу эшне оештырдык. „Игенче" колхозы членнарының гомуми җыелышы „Кызыл Сабанчы" колхозына колхоз фондыннан бурычка 60 центнер бодай бирү турында карар чыгарды. „Рәхматулла" колхозы „Марс" колхозына 80 центнер солы, „Мелешиш" колхозы „Мәгариф" колхозына 60 центнер бодай бирә.

Майоров.
Район җир бүлегенең өлкән агрономы.

Кукмара районы колхозларында язгы чәчүгә хәзерлекне үзара массовый тикшерү башланды. Тикшерү нәтиҗәсендә „Күргәзмә" колхозының язгы чәчүгә бик яхшы итеп хәзерләнгән булуы беленде. Чәчү орлыклары хәзер, машиналарга ремонт отлично билгесенә ясалган, сбруйлар да җитәрлек хәзерләнгән. Кышкы агротехника чаралары арттырып үтәлгән.

„Электро", „Тырыш" һәм „Каенлык" колхозлары да язгы чәчүгә тулысынча хәзерләнгәннәр. (ТатТАСС).

Биектау районының алдынгы колхозлары чәчү орлыклары белән шушы колхозларга социалистик ярдәм күрсәтәләр.

Буденный исемендәге колхозның членнары Калинин исемендәге колхозга бирү өчен 170 центнер орлык билгеләп куйдылар. Пушкин исемендәге колхоз „Соревнование" колхозына—200 центнер, Каганович исемендәге колхоз „Двенадцать лет Октября" колхозына—200 центнер, ОГПУ исемендәге колхоз „На страже" колхозына бирү өчен 160 центнер чәчү орлыгы билгеләп куйдылар.

(ТатТАСС).

Сталинчыл тынычлык политикасын котлыйлар

КАЗАН ҖИТЕН КОМБИНАТЫНДА

Казан җитен комбинатының барлык цехларында һәм бүлекләрендә 14 нче мартта зур митинглар булды. Митингларда агитаторлар Советлар Союзы белән Финляндия арасында төзелгән солых договорын укыдылар.

Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар бу договорны гаять зур игътибар белән тыңладылар. Договор укылып бетү белән, Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүе хөрмәтенә бердәм көчле алкышлар яңгырады.

Үзләренең фикерләрен һәм хисләрен сөйләп белдерергә теләүчеләр гаять күп булды. Эрләү фабрикасы цехларыннан берсендә орденлы Гаян иптәш Әхмәдуллинаның чыгышын митинг бердәм рәвештә каршылады. Ул болай диде:

— Пролетар революциянең йөрәге— Ленин шәһәре куркынычсызлыкта. Совет халкы үз теләгәнгә ирешге. Моның өчен без бөтен дөньяга үзенең куәтен күрсәткән героик Кызыл Армиягә бурычлыбыз.

Иптәш А. Аблаев язу машиналары заводы ашханәсе работникларына СССР белән Финляндия республикасы арасында төзелгән солых договорын укый.
М. Солтанов фотосы.

ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИ ШӘҺӘРЕНДӘ

Зеленодольски шәһәре хезмәт ияләре СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне зур канәгатьләнү белән каршыладылар. Шәһәрнең барлык предприятиеләрендә зур митинглар булды.

3 нче номерлы фанера заводының беренче смена эшчеләре митингысында 300 гә якын кеше катнашты. Митингтагылар завод партоешмасы бюросы члены иптәш Прохровның СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы белдерүен зур игътибар белән тыңладылар.

Бердәм рәвештә кабул ителгән резолюциядә түбәндәгечә әйтелә:

„3 нче номерлы фанера заводының коллективы Совет хөкүмәте тарафыннан үткәрелә торган тынычлык политикасын котлый. Без, үзебезнең тырыш хезмәтебез белән хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрергә, дөньяда беренче социалистик дәүләт булган илебезнең оборона сәләтен һәм хәрби куәтен көн саен ныгытырга сүз бирәбез.

Безнең коллектив, бөтен совет халкы белән берлектә, сөекле коммунистик партиябез тирәсенә, Совет хөкүмәте һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталин тирәсенә тагын да ныграк тупланачак".

МИНЗӘЛӘ РАЙОНЫНДА

СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында радио буенча тапшырылган хәбәрне Минзәлә районы хезмәт ияләре гаять зур күтәренкелек белән каршыладылар.

14 нче мартта иртә белән район җир бүлегендә, Татреспторгның Минзәлә бүлегендә, „Новый Путь" артелендә, Калинин исемендәге колхозда, „Сталь", „Наш труд" колхозларында митинглар булды.

Митингларда сөйләүчеләр барсы да Совет хөкүмәтенең тынычлык политикасын котладылар һәм батыр Кызыл Армиягә чиксез дәрәҗәдә соклану һәм мәхәббәт белдерделәр.

Шул ук көнне кич белән Минзәлә хезмәт ияләренең бөтен шәһәр күләмендә митингысы булды.

ЮТАЗЫ РАЙОНЫНДА

13 һәм 14 нче мартта Ютазы районының барлык колхозларында, учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә митинглар булды.

Карл Маркс исемендәге колхозның членнары, СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү уңае белән җыелган митингта кабул иткән резолюцияләрендә түбәндәгечә белдерделәр:

— Партиянең һәм хөкүмәтнең тынычлык политикасын бердәм рәвештә котлыйбыз. СССР халыкларының тыныч хезмәте турында бөек юлбашчыбыз Сталинның армый-талмый кайгыртучанлык күрсәтүен без беләбез.

ЧАЛЛЫ РАЙОНЫНДА

СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәр тиз арада бөтен шәһәргә һәм районга таралды. Һәр җирдә зур митинглар булды. Бу митингларда хезмәт ияләре Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүе турында зур күтәренкелек белән сөйләделәр.

Чаллы элеваторы эшчеләре һәм хезмәткәрләре коллективы митингысында кабул ителгән резолюциядә болай диелә:

„Без Сталинчыл тынычлык политикасын котлыйбыз, батыр Кызыл Армиябезнең лаеклы, мактаулы һәм данлы төстә бөек Ватаныбыз куркынычсызлыгын саклавы белән горурланабыз. Без тынычлык ягында торабыз, ләкин әгәр дә кем дә булса безнең изге чикләребезгә һөҗүм итәргә батырчылык итсә, ул вакытта безнең җиңелмәслек бөтен совет халкы кечкенәсеннән алып зурысына кадәр социализм илен саклауга күкрәге белән торачак һәм дошманны үз территориясендә юк итәчәк.

„Металлист", „Красная Заря", „Коллективный Труд" артельләрендә, „Главмука" бүлегендә, трактор-механика мәктәбендә һәм районның күп кенә колхозларында да зур митинглар булды.

КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫНДА

Кама Тамагы районы предприятиеләрендә һәм колхозларында СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелүгә багышланган зур митинглар булды. Кама Тамагы авылы хезмәт ияләре митингысында 450 кеше катнашты.

Пристань работнигы иптәш Батин болай белдерде:

— Су юлы транспорты работниклары коллективы солых договоры төзелүне кайнар рәвештә котлый. Бу договор безнең төньяк-көнбатыш чикләребезнең кагылгысызлыгын, куркынычсызлыгын тәэмин итәчәк. Без производствода тагын да яхшырак эшләргә, шуның белән илебезнең оборона көчен ныгытырга сүз бирәбез.

Комсомолец иптәш Насибуллин:

— Без комсомолецлар һәм колхоз яшьләре, колхоз производствосын армый-талмый ныгытачакбыз һәм сугыш белемнәрен регуляр рәвештә өйрәнәчәкбез,—ди.

Митингта катнашучылар резолюция кабул иттеләр. Бу резолюциядә алар хөкүмәтебезнең тынычлык политикасын кайнар рәвештә котлыйлар.

ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫНДА

Әгерҗе районының барлык колхозларында, предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелүгә багышланган митинглар булды.

Район үзәгендә булган митингта 100 кеше катнашты. Митингка катнашучылар Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүен зур шатлык белән котладылар.

МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА

14 нче мартта Мамадышта хезмәт ияләренең бөтен шәһәр митингысында 400 кеше катнашты. Митингта катнашучылар СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турындагы белдерүне чиксез зур шатлык белән каршыладылар.

Бердәм рәвештә кабул ителгән резолюциядә болай әйтелә:

— Без, Мамадыш шәһәре хезмәт ияләре, СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы белдерүне шатлык һәм горурлык белән каршыладык. Сталинчыл тынычлык политикасын чын күңелдән котлыйбыз.

Шулай ук, „Агробаза", „Пятилетка" совхозларында, „Кызыл Флаг", „Оборона" һәм башка колхозларда, районның учреждениеләрендә митинглар булды.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Вологдадагы Дәүләт Педагогия институтына һәм Вологда шәһәренең 23 нче мәктәбенә иптәш В. М. МОЛОТОВ исмен бирү турында

Вологдадагы җәмагат оешмаларының үтенечен канәгатьләндереп Вологдадагы Дәүләт Педагогия Институтына һәм Вологда шәһәренең 23 нче мәктәбенә иптәш В. М. Молотов исмен бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 16 март, 1940 ел.

ФРАНЦИЯДӘ ХӨКҮМӘТ КРИЗИСЫНЫҢ ӨЛГЕРЕП КИЛҮЕ ТУРЫНДА РЕЙТЕР АГЕНТЛЫГЫНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 15 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, „Финляндия белән СССР арасындагы сугышның тәмамлануы [illegible] унае белән" Парижның политик даирәләрендә зур тынычсызлану хөкем сөрә. Сенатның кичке утырышы 3 сәгать чирек дәвам иткәннән соң бүгенгә күчерелде. Сенатның кичке утырышы [illegible] сенда „Хәзерге хәлгә күп кенә даирәләрдә министрлар кризисын хәл итү [illegible]" Аннары агентлыкның хәбәр итүенчә, [illegible] кабинетның составын [illegible] бүлергә, аерым алганда „яңа" чит ил эшләре министре [illegible] хәзергә политика Даладье алып бара.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Авыл хуҗалыгына большевикларча җитәкчелек итәргә

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев реченнән

Иптәшләр! Хәзер Татарстан партоешмасы алдындагы, аерым алганда авыл партия оешмалары алдындагы иң сугышчан бурычларның берсе—язгы чәчүгә хәзерлектән гыйбарәт. Югары иген уңышы өчен партиянең XVIII нче съезды карарлары һәм иптәш Сталин күрсәтмәләре нигезендә большевикларча көрәшергә, ашлык өчен көрәш—социализм өчен көрәш икәнлеген без һәр вакыт истә нык тотарга тиешбез. Шушы бурычны үтәү өчен, быел һәрбер гектардан йөз пот иген уңышы алу өчен Конференция барлык партоешмаларының игтибарын Татарстан авыл хуҗалыгының арттылыгын бетерүгә тупларга тиеш.

Бездә еш кына: ни өчен Татарстанның күп кенә колхозлары дәүләт алдындагы йөкләмәрен үти алмадылар, ни өчен иген уңышы түбән, ни өчен байтак колхозларда җәмагатьләштерелгән терлекләргә азык җитешми? дигән сорауларны ишетергә туры килә. Чөнки партоешмалар, совет һәм җир органнары иген уңышын күтәрү турында XVIII нче съезд карарларын үтәү өстендә аз эшләделәр. Ул сорауларга башкача җавап бирергә мөмкин түгел. Әнә шуның өчен дә язгы чәчүгә хәзерлек эше, кабатлап әйтәм, бөтен Татарстан партоешмасы алдында иң сугышчан бурыч булып тора.

Орлык мәсьәләсе—чәчүнең нигезе. Бу тармактагы бурыч барыбыз өчен дә ачык: безгә чәчүлек орлыкларын урыннардан табарга кирәк. Табу гына җитми, орлыкның сыйфаты да, сортлары да яхшы булырга тиеш. Чәчү орлыкларын урыннарда табарга мөмкин булуы турында берничә факт китерәм. Әгәр дә чәчү орлыклары фондларын тикшерүгә чаклы Беренче Май районы 16.370 центнер ссуда сораган булса, хәзер, тикшерүдән соң, алар чәчү орлыклары 43 колхозга җитәрлек булу белән үзләре дә риза. Бу мәсьәлә буенча хәл Актаныш районында да шулай тора. Ссуда сорап заявка биргән Әгерҗе, Арча, Кайбыч һәм башка районнар да орлыкны үзләрендә табу чарасына керештеләр. Димәк, без бу өлкәдә зур эшлеклелек күрсәтергә һәм чәчү орлыкларын кирәк күләмдә үзебездә таба алабыз һәм табарга тиешбез.

Чәчү орлыкларын туплауда колхозара ярдәм оештыру аеруча әһәмиятле мәсьәлә булып тора. Бу өлкәдә Теләче район оешмалары яхшы инициатива күрсәттеләр. Алар бу эшне зур җиддилек белән оештырдылар. Колхозара ярдәм күрсәтү турында 31 колхозда җыелышлар үткәрделәр һәм карарлар кабул иттеләр. „Кызыл Яңбулат" колхозы кебек бурычка 600 центнер орлык бирделәр. Колхозара ярдәм тәртибендә бирелә торган орлыкларның яртысы инде ташып куелды. Һич шик юк, мондый зур ярдәмне башка колхозлар да оештырырлар, чәчүне большевикларча үткәрергә булышырлар. Бу ярдәмне тик оештыра белергә генә кирәк.



Чәчүлек орлыкларны сортлыга алмаштыру буенча да безнең алда зур эш тора. Ләкин ул әле бик акырын бара. Алмашу планының үтәлеш темпы ике декадада бары 4 процентка гына үсте. Чәчүлек орлыкларын алмашуны чана юлы бар вакытта тәэмин итәргә кирәк.

Чәчү орлыкларына анализ ясау да гаять акырын бара. Югары Ослан районында бу эш 30 процентка гына үтәлгән. Бу эш Питрәч һәм Столбище районнарында да яхшы тормый. Чәчүлек орлыкларын кондициягә җиткерү өчен барлык чаралар күрелергә, барлык машиналар тупланган булырга тиеш.

Шуннан соң иптәш Матвеев агротехника чараларын үткәрү мәсьәләләренә күчеп болай ди:

— Агротехника чараларын тулы һәм дөрес үткәрү—югары иген уңышы алуның төп нигезләреннән берсе. Бу тармакта яхшы эшләүче районнар да бар. Мәсәлән, Актаныш районында кар тоту планы 135 процент, тирес чыгару планы 157 процент үтәлгән. Калинин районында кар тоту планы—100 процентка, тирес чыгару—137 процентка җитте. Шулар белән бер рәттән иген уңышы өчен быел да начар көрәшүче районнар бар әле. Мәсәлән, Тәкәнеш районында кар тоту планы 37, тирес чыгару—36 процент кына үтәлгән. Бу чараларны үткәрү буенча Югары Ослан, Тәмте районнары гафу ителмәслек эшлексезлек күрсәтәләр.

Кышкы агротехника чараларын һәм язгы-җәйге кыр эшләрен үткәрүдә хезмәтне звенолар нигезендә оештырырга кирәк. Партия оешмалары звенолар төзү эшенә якыннан торып җитәкчелек итәргә, бозуларга юл куймаска тиешләр. Звенолар кәгазьдә генә түгел, бәлки югары иген уңышы алу өчен көрәштә төп звено булырга тиеш. Шунлыктан, звенолар турында кабинетларда сөйләнеп утырудан практик эшкә, бу турыда XVIII нче съезд күрсәтмәләрен һич кичекмәстән үтәргә керешергә кирәк.

Чәчүне тулы хәзерлек белән каршы алу һәм аны иң кыска срокларда төгәлләү өчен тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына, инвентарьга ремонт ясау хәл иткеч чаралар булып тора. Ләкин ремонт темпы һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Шунлыктан, ремонтның темпын да, сыйфатын да кискен рәвештә көчәйтергә кирәк. Моның өчен хезмәтне оештыруны яхшыртырга, тракторларга запас частьләр ясауны, кайтартуны ашыгычлык белән тәмамларга һәм элек эшләгән тракторчыларның барсын да МТС ларга кайтарту эшенә керешергә кирәк.

Язгы чәчү мәйданы түңгә сөрелеп бетмәгәнлектән, яз көне бик зур мәйданны сөрү бездән гаять зур көч таләп итәчәк. Без сөрүне 2—3 көн эчендә үткәрергә тиеш булабыз. Димәк, бу зур эшне башкару өчен тракторлардан гына түгел, бәлки бөтен ат көченнән файдалануны да күз алдында тотарга кирәк. Яз көне сөрүнең тирәнлеге кимендә 20—22 сантиметр булырга тиеш. Шушы уңай белән, „Правда" газетасында язылган мәкаләне, үткән көз түңгә сөрү күп кенә районнарда сай булуны тулысынча дөрес дип исәплим.

Аннан соң, иптәш Матвеев болай ди:

— Совнарком һәм Наркомзем аппаратларына ярдәм итәргә, аларның эшен яңа баштан корырга, аларга карата таләпне көчәйтергә кирәк. Шуның белән бергә алар эшен Өлкә Комитеты үзе башкару практикасына чик куелырга тиеш.

Колхозларда башлангыч партоешмалар турындагы мәсьәләгә килгәндә, бездә бу эш бик нык аксый әле. Райкомнарның аларга җитәкчелек итүләре, ярдәм күрсәтүләре һич тә җитәрлек түгел. Бездә колхозларда башлангыч партоешмалары бөтенләй булмаган районнар да бар әле. (Чаллы һәм Юдино районнары). Ә башлангыч партоешмалар булган һәм алар яхшы эшләгән колхозларда авыл хуҗалыгы эшләренең үтәлеше бөтенләй башкача. Мәсәлән, Әтнә районының Киров исемендәге колхозын гына алып карыйк. Бу колхозда иген уңышы да яхшы була, терлекчелек тә алга китә, политик тәрбия эшләре дә яхшы куелган. Райкомнарның бурычы—колхоз партоешмаларына җитәкчелек итү эшен беренче бурыч итеп куюдан һәм якыннан торып ярдәм итүдән, аларны иң яхшы колхозчыларны һәм авыл интеллигенциясе хисабына үстерүдән, сугышчан оешма итүдән гыйбарәт.

Татарстан партия оешмасы ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары һәм иптәш Сталин күрсәтмәләре белән коралланып, авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүнең яхшыртыр һәм алда торган катлаулы һәм җаваплы бурычларны үтәү өчен барлык коммунистларны, барлык колхозчыларны һәм МТС, совхоз эшчеләрен туплар! (Кул чабулар).

Иген уңышын кискен рәвештә күтәрергә

ВКП(б) ның Чистай райкомы секретаре иптәш Воробьев реченнән

Отчет докладында 1939 нчы елда авыл хуҗалыгы эшләренең йомгаклары канәгатьләнмәслек икәнлеге күрсәтелде. Бу, Татарстан партоешмасы авыл хуҗалыгы өлкәсендә партиябезнең карарларын һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләрен үтәп җиткермәве дигән сүз.

Дөрес, соңгы ике елда иген уңышы өчен климат шартлары начар булды. Ләкин, шуңа да карамастан, бездә табигатьнең стихияләренә каршы уңышлы көрәшеп, югары иген уңышы алуны тәэмин итәргә мөмкин иде. Билгеле булганча, иптәшләр, җирне парга сөрү, аны яхшылап эшкәртү һәм тәрбияләп тору, җирне иртә сөрү кебек чаралар корылыкка каршы көрәштә агрономия чараларының иң әһәмиятлеләре.

Бу чараларны Татарстанда ничек үткәрәләр соң? Әйтергә кирәк: соңгы ике елда алар агрономия кагыйдәләре буенча билгеләнгән срокларда үткәрелмәделәр генә түгел, бәлки хурлыклы рәвештә өзелделәр. 1938 нче елда пар сөрү планы билгеләнгән срокка 51 процент үтәлгән булса, 1939 нчы елда 26 процент кына үтәлде. Пар җирләрен икенче кат культивацияләү һәм түңгә сөрү эшләрендә дә шундый ук хурлыклы саннарны күрергә туры килә. Шулай итеп, республикабызда трактор паркының үсүенә һәм колхозлардагы тарту көчләренең артуына да карамастан, корылыкка каршы көрәштә бу төп чаралар елдан-ел үтәлми килделәр. Бу инде үз чиратында язгы чәчүдә тарту көчләренең җитешмәвенә һәм язгы кыр эшләренең соңга калуына китерде.

Югары иген уңышы алуның ефремовча эшләү методларын тизрәк үзләштерү өчен көрәшәсе урында, җир органнарының кайбер работниклары бу хәрәкәткә карата, имештер, ефремовчылар тарафыннан Алтай крае шартларында кулланылган агрономия чараларын Татарстан шартларында куллану мөмкин түгел, ә мөмкин булмаганны эшләүнең файдасы юк, дип консерватив настроениегә бирелделәр.

„Большевик" һәм „Партийное строительство" журналларында ефремовчылар эшенә анализ ясап бирелгән материаллар җир органнарында эшләүче аерым работниклар тарафыннан таратылган зарарлы фикерләрне юкка чыгардылар. Ефремовчылар кулланган агрономия чараларын Татарстан шартларында куллану да мөмкин һәм кулланырга кирәк. Ләкин бу сүз генә бер эш түгел. Ефремовча эшләп, югары иген уңышы алу өчен, Татнаркомзем җитәкчелегендә һаман яшәп килгән җебегәнлекне, эшне үз агымына куюны бетерергә, уйлап һәм тырыш эшләргә, колхозларга, бригадаларга һәм звеноларга системалы рәвештә, көн саен булышырга һәм оператив җитәкчелек итәргә кирәк.

Конференциядән соң, ВКП(б) Өлкә Комитетының яңа составы тиешле нәтиҗәләрне ясар һәм 1940 нчы елда республикабызда югары иген уңышы алу өчен көрәштә авыл хуҗалыгы эшләренә җитәкчелекне тәэмин итәрлек чаралар күрер.

Эштәге кайбер кимчелекләр

Сарман райкомы секретаре иптәш Тимерханов реченнән

Иптәш Алемасов үзенең докладында Сарман МТС ының ремонт эшендә артта калуын бик дөрес тәнкыйтьләде. Бу артта калуның сәбәбе нәрсәдә соң? Минемчә, моның төп сәбәбе ремонт эшләренең Наркомзем тарафыннан дөрес планлаштырылмавында. Наркомзем планы буенча Сарман МТС ы 30 машинаны Карамалы МТС ында ремонтларга тиеш иде. Бу үтәлмәде. Райком бу мәсьәләне Наркомзем алдына куеп, безнең ремонт эшен Бөгелмәгә беркетүне сорады. Бик озак бәхәсләшкәннән соң, бик соңга калып кына Наркомзем безнең сорауны канәгатьләндерде. Гомумән, бу мәсьәләдә Наркомзем МТС ларга дифференциаль җитәкчелек итми.

ВКП(б) Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегенең эше турында шуны әйтергә кирәк. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" басылып чыгу уңае белән партия пропагандасының куелышы турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты карарының үтәлешен тикшерү өчен пропаганда һәм агитация бүлеге безнең районга Закиров һәм Музагитов иптәшләрне җибәрде. Иптәш Мөхәметов уенча, тикшерү нәтиҗәләре Өлкә Комитеты бюросында куелырга тиеш булган һәм ул, урып-җыюга хәзерлекнең иң җаваплы чорында, районның күп кенә җаваплы работникларын Өлкә Комитетына чакыртып алды. Казанда 2—3 көн торганнан соң безгә бу мәсьәләнең бюрода куелмаячагын белдерделәр. Шуны әйтергә кирәк: хәтта иптәш Мөхәметов тикшерү нәтиҗәләрен безгә аңлатырга да вакыт тапмады.

Узган конференциядә күп кенә делегатлар район үзәкләрендә клублар булдыру кирәклеге турында сөйләделәр. Татсовнарком председателе урынбасары Сөләйманов һәм Татнаркомпрос—Контюков иптәшләр бу эштә ярдәм итмәделәр генә түгел, бердән-бер клубны башка оешмага алып биреп, безне бөтенләй клубсыз калдырдылар. Нәтиҗәдә, киңәшмәләрне күрше авылларда үткәрергә туры килә.

Партия безгә, район җитәкчеләренә, җаваплы бурычлар йөкләде һәм, шик юк, без ул бурычларны үтәрбез.

Мөмкинлекләрдән тулы файдаланырга

Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш Черзор реченнән

1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары, Өлкә Комитет отчетында күрсәтелгәнчә, канәгатьләнмәслек булдылар.

ВКП(б) Үзәк Комитеты, СССР Совнаркомы һәм иптәш Сталин авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә гаять зур әһәмият бирәләр. 1939 нчы елда ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы колхозларны оешу - хуҗалык ягыннан тагын да үстерү һәм колхозларның җәмагать хуҗалыгын ныгытуга юнәлдерелгән күп кенә карарлар кабул иттеләр.

Ни өчен соң без, беренче чиратта җир органнары работниклары, үткән ел яхшы нәтиҗәләргә ирешә алмадык. Биредә күп сәбәпләр китереп торуның кирәге юк. Без авыл хуҗалыгы эшләрен үз вактында башкаруны тәэмин итмәдек, хезмәтне дөрес оештыруга җитәрлек әһәмият бирелмәде, хезмәт дисциплинасы йомшак булды һәм агротехника чаралары тиешенчә үткәрелмәде.

Иген уңышын алу планы үтәлмәде, тракторлар белән эшләү планы бары 77 процент үтәлеп калды. Татарстан республикасы тракторлар эше буенча берничә ел буена Союзда алып килгән алдынгылыгын югалтты.

Колхозларның дәүләт алдындагы йөкләмәләре шулай ук үтәлмәгән, ә ялгыз хуҗалыкчылар секторы буенча бу эш өзелде. Терлекчелекне үстерү һәм яңа фермалар оештыру планы да үтәлмәде.

Отчет докладында иптәш Алемасов һәм чыгып сөйләүче иптәшләр Татнаркомземның һәм аның урыннардагы органнарының төп җитешсезлекләре һәм ялгышларына тукталдылар. Бу замечаниеләр һәм булган тәнкыйть бик дөрес һәм мин аны кабул итәм. Безнең бурыч—күрсәтелгән җитешсезлекләрне һәм ялгышларны тизрәк бетерүдән гыйбарәт.

Мин Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгына җитәкчелеге турында әйтмәкче булам.

Өлкә Комитеты авыл хуҗалыгы турында чыгарган карарларының үтәлешен бик сирәк тикшерде. Авыл хуҗалыгына җитәкчелек Өлкә Комитеты тарафыннан да гомумән булды. Аерым участокларга, колхозларга, районнарга карата конкрет эш, конкрет җитәкчелек җитәрлек булмады.

Колхозларда даими звенолар оештыру турында Өлкә Комитеты карарының үтәлеше бер генә районда да тикшерелмәде. Шушы елның 17 нче февралендә Өлкә Комитеты механизатор кадрлар хәзерләүнең барышы турында карар кабул итте. Шуннан соң карарның мәктәпләрне тәэмин итү буенча булган өлешен Татсовнаркомның ничек үтәве турындагы мәсьәлә Өлкә Комитеты алдына берничә тапкыр куелды. Ләкин бу мәсьәлә хәзергә кадәр хәл кылынмаган. Өлкә Комитетының 1940 нчы ел 7 нче февральдә чыгарган карарында промышленность предприятиеләренең авыл хуҗалыгына булышлыгын оештыру буенча практик чаралар эшләү, аерым алганда МТС ларга һәм МТМ нарга белгечләр бирү, төрле җиһазлар һәм инвентарь бирү мәсьәләсе куелды. Бу карарның да үтәлеше тикшерелми. Ә шәһәр оешмалары бу карарны үтәмиләр.

Хәзер шәһәр тирәсе яшелчәчелек хуҗалыкларында парниклар хәзерләү эше бара. Бу хуҗалыкка һәрбер предприятие булышлык итәргә тиеш. Ләкин без моны күрмибез әле. Шәһәр оешмалары, бигрәк тә партиянең шәһәр комитеты бу эштән читтә калмаска, шәһәр тирәсе хуҗалыгының эшенә ярдәм итәргә тиешләр.

Иптәш Алемасов һәм фикер алышуларда катнашучы иптәшләр авыл хуҗалыгы алдында торган төп бурычларны әйттеләр инде.

Татарстанның күп кенә районнары елгаларга бай. Ләкин бу елгалардан җир сугаруга файдалану эше оештырылмаган. 1933—34 нче елларда сугару өчен корылган чыгырлар ташландык хәлгә китерелгәннәр. Бу чыгырларга ремонт ясарга кирәк. Һәрбер колхозда җирне сугару чараларын күрергә кирәк. Урман полосалары утырту буенча шулай ук бер нәрсә дә эшләнми диярлек. Хәтта утыртылган агачларны да терлекләрдән әрәм-шәрәм иттерү фактлары бар. 1940 нчы елда без кимендә 515 колхозда урман полосалары утырту үткәрергә тиешбез.

Иптәшләр, партия һәм хөкүмәт карарларын, ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү турында иптәш Сталин күрсәтмәсен, өч республика арасында төзелгән социалистик ярыш договорын тулысынча үтәүгә барлык колхозчыларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен туплап, партиянең Татарстан оешмасы 1940 нчы елда республиканың авыл хуҗалыгындагы арттылыгын бетерер. (Кул чабулар).

Халык мәгарифе органнарына игтибарны көчәйтергә

Татарстан Мәгариф Халык Комиссары иптәш Контюков реченнән

Сталинчыл бишьеллыкларның җиңүе халык мәгарифе өлкәсендә яңа гаять зур бурычларны—Сталинчыл өченче бишьеллыкта шәһәрдә гомуми урта белем алуга, авылларда һәм барлык милли республикаларда 7 еллык белем алуга ирешү бурычын илебез алдына куярга мөмкинлек бирде. Партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан куелган бу бурычны тормышка ашыруда илебез ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм иптәш Сталин җитәкчелегендә зур уңышларга ирешәте. Хәзерге вакытта безнең Татарстан республикасында гына да 557.200 бала укый. Быел 2 меңнән артык белгечләр—яш укытучылар совет укытучылары армиясе сафларын тулыландырдылар. Бездә 1940 нчы уку елының беренче яртысын йөзләрчә укытучылар укыту эшенең югары күрсәткечләре белән тәмам иттеләр.

Шундый уңышлар белән бергә, гомуми мәҗбүри уку өлкәсендәге кимчелекләрне дә әйтеп үтәргә кирәк. Бу өлкәдә Татарстан быел да артта кала. Безнең кайбер районнарыбызда 200 — 300 гә якын бала укуга тартылмаган. Болардан тыш күп кенә укучылар һичбер төрле сәбәпсез укуларын ташлаганнар. Кайбер мәктәпләр уку елының беренче яртысында түбән өлгереш бирделәр.

Шуны әйтергә кирәк. Укучыларда сөйләү һәм язу речьләрен яхшырту буенча системалы эшнең булмавы укыту эшендәге, аеруча башлангыч һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә рус телен укыту эшендәге төп кимчелекләрнең берсе булып тора. Мәктәпләрдә тәрбия эшләре йомшак куелган. Халык мәгарифе органнары һәм комсомол оешмалары коммунизм төзүчеләрне тәрбияләүдә республикабызда булган зур мөмкинлекләрдән (техника, экскурсия станцияләре, балалар киносы, пионерлар клубы һ. б.) тулысынча файдаланмыйлар. ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы карарлары тулысынча үтәлми әле. Турыдан-туры әйтергә кирәк. Партиянең кайбер район комитетлары X нчы пленум карарларын ничек үтәүләре турында комсомол оешмаларының эшләре белән кызыксынмаганнар.

Гомуми мәҗбүри укыту буенча дәүләт планы үтәлмәвенең төп сәбәбе шунда ки, район мәгариф бүлекләре һәм Наркомпрос бу мәсьәләне тулы оештыручылар була алмадылар, бу эшкә комсомолны, эшчеләрне, колхозчыларны һәм интеллигенцияне тиешле дәрәҗәдә тупламадылар. Күп кенә авыл советларында балаларга мәктәпкә йөрү шартлары тудырылмаган.

Наркомпрос эше турында иптәш Алемасов докладындагы һәм аерым делегатларның чыгышларындагы тәнкыйть бик урынлы. Биредә булган тәнкыйтьне искә алып, безнең җитәкче работникларыбыз халык мәгарифе органнарының эшен яхшыртуга үз игтибарларын көчәйтерләр.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Ике мөһим мәсьәлә турында

ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Бычков реченнән

ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары, иптәш Сталинның тарихи докладындагы бөек идеяләр белән коралланган Татарстан оешмасы отчет чоры эчендә социализм төзелешенең барлык өлкәләрендә, һич шиксез, зур уңышларга ирешә. Ләкин Өлкә Комитетының практик эшендә күп кенә җидди кимчелекләр дә бар. Конференция делегатлары бу кимчелекләрне бик урынлы тәнкыйтьләделәр, киләчәктә аларны бетерү буенча конкрет юллар күрсәттеләр.

Мин үземнең чыгышымда ике мәсьәләгә—күп станокчылар хәрәкәтенә җитәкчелек һәм колхоз сәүдәсен большевикларча оештыру мәсьәләсенә тукталырга уйлыйм.

Турыдан-туры әйтергә кирәк, иптәшләр, ВКП(б) ның Өлкә һәм Шәһәр комитетлары тарафыннан күп станокчылар хәрәкәтенә җитәкчелек һич тә канәгатьләнерлек булмады, бу зур кимчелекләрнең берсе. Өченче бишьеллыкны уңышлы үтәүдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү гаять зур роль уйный, ә күп станокчылар хәрәкәте хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә турыдан-туры бәйләнгән. Бу хәрәкәткә дөрес җитәкчелек итү өчен аның белән якыннан таныш булырга, аны җентекләп өйрәнергә кирәк. Аерым предприятиеләрдә күп станокчылар хәрәкәтен дөрес аңламау һәм аны бозу фактлары бар.

Менә берничә мисаль. Житен комбинаты эшчеләреннән күп станокчылар Долгих, Захарова, Егорова, Пустынникова һ. б. иптәшләр 2 станокта эшләгән вакытта норманы үтәп һәм арттырып үтәп килгән булсалар, 3 станокка күчү белән ким үти башлаганнар. Предприятие җитәкчеләре бу мәсьәләгә бик өстән генә караганнар, норма үтәлмәүнең сәбәпләрен тикшермәгәннәр. Күп станокта эшләүчеләр һәр станок буенча да нормаларны тутырсыннар һәм арттырып үтәсеннәр өчен аларга барлык шартларны тудырырга кирәк. ВКП(б) ның Өлкә һәм Шәһәр комитетлары бу гүзәл хәрәкәткә якыннан торып конкрет җитәкчелек итәргә тиешләр.

Икенче мәсьәлә—колхоз сәүдәсе турында. Бөтенебезгә дә билгеле булганча, шәһәр халкының тормышында авыл хуҗалыгы продуктлары зур урын алып торалар. Колхоз базары шәһәр халкының ит, май, сөт, бәрәңге кебек авыл хуҗалыгы продуктлары буенча булган сорауларын канәгатьләндерергә тиеш иде, ләкин январь аеннан башлап, бигрәк тә февраль һәм март айларында колхозлардан шәһәргә китерелә торган продуктлар бик нык кимеделәр. Шунын нәтиҗәсе буларак, ашамлык нәрсәләренең бәяләре соңгы вакытта бик нык күтәрелде. Чөнки февраль аенда, оештырылган рәвештә бер колхоздан да шәһәргә продуктлар китерелмәде. Спекулянт элементлар бу хәлдән файдаланып, продуктларның бәяләрен күтәрделәр. Наркомторг базарга бер төрле дә йогынты ясамады, эшлексезлек күрсәтә, ә базарлар идарәсе продуктлар бәяләрен теркәү белән генә канәгатьләнә. Әйтергә кирәк, Казанда бер оешма да колхоз сәүдәсе мәсьәләсе белән чынлап шөгыльләнми. Шулай ук, Казанга якын булган районнарның райторг һәм райсоветлары да бу мәсьәлә белән бер дә кызыксынганнары юк. Ә бу районнарның райсоветлары һәм райторглары район үзәгендәге сәүдә эшен оештыру белән генә канәгатьләнеп калмыйча, шәһәр колхоз базарына ярдәм итү эшен дә карарга тиешләр иде. Озакламый яз башлана, юллар өзеләчәк, бу чорда шәһәргә керә торган продуктлар тагын да кимиячәк. Шунлыктан колхоз сәүдәсен оештыру мәсьәләсенә аеруча игтибар бирергә тиешбез. Беренче чиратта Наркомторг бу эшне планлаштырырга, конкрет җитәкчелек итәргә тиеш. Колхоз базарында районнар өчен сату урыннары, ларьклар хәзерләргә, колхоз базарларына продуктлар китерүчеләр өчен шартлар тудырырга кирәк.

Казандагы предприятиеләр колхоз сәүдәсен яхшыртуда күп нәрсә эшли алалар. Башка шәһәрләрдә бу нәрсә эшләнә дә. Серго Орджоникидзе исмендәге завод, Мехкомбинат, Ленин исмендәге завод, 4 нче ясалма каучук заводы, Жиркомбинат һәм башкалар, үзләренең автомашиналары белән колхозлардан продукт ташу мәсьәләсендә конкрет ярдәм оештыра алалар һәм оештырырга тиешләр. Бу эштә Казан тимер юлына да күп нәрсә эшләргә мөмкин. Димәк, колхоз сәүдәсен яхшырту өчен бик күп мөмкинлекләр бар, тик алардан файдалана белергә генә кирәк. Базарлар идарәсе базарларны яхшырту өчен, культуралы сәүдә оештыру өчен билгеләнгән акчаны бер елны да тотып бетергәне юк, хәзерге вакытта аның 2 миллион сумнан артык акчасы бар. Ә безнең базарларыбыз һаман да яхшыртылганы юк әле.

Колхоз сәүдәсен яхшыртуда әһәмиятле мәсьәләләрнең тагын берсе—ул Татарстанга күрше республикалардан, өлкәләрдән продукт китерүне оештыру. Мәсәлән, Киров өлкәсе колхозчылары, Марий һәм Чувашстан республикасы колхозчылары безнең колхоз базарларыбыз белән бик нык бәйләнгәннәр, тик бу эшне оештыруга моңарчы тиешле игтибар гына бирелмәде. Хәзерге көндә бу республикалардан Казанга күпләп алма, ит, май, бәрәңге кебек продуктлар кертеләләр. Ләкин алар оештырылмаган рәвештә кертелгәнлектән, күп вакыт спекулянтлар кулына төшеп югары бәяләр белән сатылалар.

Колхоз сәүдәсен яхшырту эше барлык оешмаларның, беренче чиратта Наркомторг, Шәһәр Советы Башкарма Комитетының игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Шушы мәсьәләләргә бәйләнгән тагын бер мәсьәләне мин райком секретарьлары игтибарына куярга уйлыйм, ул—яшелчәчелек мәсьәләсе. ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты райкомнар белән берлектә бу мәсьәлә буенча күп кенә конкрет чаралар күрә ала. Казан шәһәренең хезмәт ияләре яшелчә белән тулысынча тәэмин ителергә тиешләр. Парниклар төзүдә колхозларга шәһәр ярдәм итәргә тиеш. Мәсәлән, һәрбер предприятиедә диярлек төзелештән калган агач материаллар, пыялалар һәм башкалар бар, боларны колхозларга парниклар төзү өчен җибәрергә кирәк. Шулай ук, шәһәр колхозларга эшче көчләре бирү белән, бигрәк тә утау, урып-җыю вакытларында транспорт бирү һәм башкалар белән ярдәм оештыра ала.

Димәк, колхоз сәүдәсен яхшырту өчен, Казан шәһәре хезмәт ияләрен кирәкле продуктлар белән тәэмин итү өчен бездә чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Боларның барсыннан да тулысынча файдаланырга, колхоз сәүдәсен большевикларча оештырырга тиешбез.

Комсомолның көче—партия җитәкчелегендә

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. Перов реченнән

Комсомолның Татарстан оешмасы отчет чорында оешу һәм политик яктан шактый ныгыды. Ул үзенең сафларын иң алдынгы эшче, колхозчы яшьләр һәм интеллигенция исәбенә үстерде. 1939 нчы елда республикабызның алдынгы яшьләреннән 42 меңнән артык кеше комсомолга кабул ителде. Пионер отрядлары шактый үсте һәм ныгыды. Комсомол оешмаларының тормышы һәм эше нык кына үзгәрде: алар республикабызның дәүләт һәм хуҗалык төзелешенә бәйләнгән мәсьәләләргә күбрәк игтибар бирә башладылар.

Ләкин, комсомол оешмалары эшенең беркадәр яхшыруы хәзерге вакытта безне һич тә канәгатьләндерә алмый әле. Безнең эштә җидди кимчелекләр һәм, хәттә, ялгышлар бар. Комсомолның Татарстан оешмасы эшендә зур кимчелек—мәктәпләрдә комсомол эшенең бик начар, канәгатьләнмәслек булуында. Безнең мәктәпләребез балаларны коммунистик тәрбияләү өчен чакырылганнар. Бу өлкәдә кайбер эшләр эшләнгән, шулай да әле күп кенә мәктәпләрдә дисциплина һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәктәпләрдә аерым укучылар тарафыннан заданиеләрне үтәмәү, уку режимын бозу һәм хулиганлык, укытучыларны кимсетү фактлары бар. Татарстанда үткән уку елында 42 мең 312 укучы укудан өлгермәде. Наркомпрос органнары, комсомол оешмалары безнең мәктәпләрдә укудан өлгерешне күтәрү өчен менә моннан кирәкле нәтиҗәне ясарга тиешләр иде. Ләкин бу эшләнмәде. 1939—1940 нчы уку елының беренче яртысында укучыларыбызның өлгереше яхшырмады. Мисальгә Кызыл Армия районы Каргалы мәктәбен алырга мөмкин. Анда 541 укучының 250 се укудан өлгерми. Комсомол оешмалары кайбер укучыларның мәктәпкә йөрмәү фактларын читләтеп үтәләр. Комсомол оешмалары мәктәпләрдәге комсомолецларның укудан өлгерүләре өчен тиешенчә көрәшмиләр. Казанда 85 нче номерлы мәктәптә 72 комсомолецның 23 се укудан өлгерми. Дисциплина мәсьәләсе күп мәктәпләрдә начар тора. Бондюг мәктәбендә бер укучы укучылар алдында география картасын утка яндырган. Мәктәпләрдә шундый хулиганлык фактлары аз түгел. Мәктәпләрдәге бу начар күренешләргә партиянең өлкә оешмасы алдында, барыннан да элек, комсомол оешмалары һәм Наркомпрос органнары җаваплылар.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы карарыннан соң бу өлкәдә кайбер эшләр башкарылды. Ләкин болар гына безне һич тә канәгатьләндерә алмыйлар. Наркомпрос та үзенең эш стилен үзгәртергә, укытучыларга игтибарсыз карауларны ахрынача бетерергә, халык укытучысының авторитетын комсомол белән берлектә ныграк күтәрергә тиеш.



Мәктәпләр эшен яхшыртуда без партия оешмаларыннан кирәкле булышлыкны алырга тиешбез. Комсомол оешмалары үзләре генә, партоешмаларның булышлыгыннан башка бу зур мәсьәләне—безнең мәктәпләрнең эшен тамырыннан яхшыртуны тиешле югарылыкка күтәрә алмаячаклар.

Партиянең күп кенә район комитетлары мәктәпләр мәсьәләсе белән хәзергә кадәр кирәгенчә шөгыльләнмиләр, укытучыларның тормышы белән кызыксынмыйлар. Мәсәлән, Питрәч районында тел һәм әдәбият укытучысы, ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Сметанин квартира мәсьәләсе буенча райкомга мөраҗәгать итәргә мәҗбүр була. Ул үзенә карата хулиганнарча, махаевча караш барлыгы турында райкомның элекке секретаре иптәш Алексеевка һәм район советының башкарма комитеты председателенә әйтә. Шул вакыт райком секретаре: „Син, димәк, безне контрреволюциядә гаеплисең, мәсьәләне райкомда куярга туры килер“ ди. Аның турында бюрога куеп тикшермәсәләр дә, укытучыны туры әйткәне өчен актив җыелышында кыздыралар. Квартира шартлары тәэмин ителмәгәнлектән, укытучы башка районга китә. Районда укытучыларга шундый караш факты бер генә түгел. Питрәч авылы мәктәбендә генә дә 1934 нче елдан алып 100 дән артык укытучы алмашынган. Укытучыларга шундый караш мәктәпнең бөтен эшенә начар йогынты ясый. Бу мәктәптә 1939—1940 нчы уку елының беренче яртысында өлгереш 49 процент кына була.

Партия райкомнары мәктәпләрдә Москваның „Серп и Молот“ заводы эшчеләре мөраҗәгатен киң рәвештә тикшерү һәм мәктәпләр эшен тамырыннан яхшырту эшенә бөтен җәмагатьчелекне тупларга, бу эштә комсомолга практик булышлык күрсәтергә тиешләр. Без мәктәпләрнең эшен ныгытуыбыз белән дәүләтебезнең эшен ныгытуга ярдәм иткәнлегебезне һәр вакыт хәтердә тотарга тиешбез.

Иптәш Алемасов үзенең докладында, производстводан аермыйча тракторчылар хәзерләү эшен өзү өчен комсомол оешмаларын бик дөрес тәнкыйть итте. Без бу эшкә оператив җитәкчелекне тәэмин итә алмадык. Дөрес, кайбер райкомоллар (мәсәлән, Буденный ройкомолы) бу эшне яхшы башкардылар. Күп кенә райкомоллар (Балык Бистәсе, Югары Ослан һ. б.) хатын-кыз яшьләрдән тракторчылар хәзерләү эшен өзделәр. Бу мәсьәләдә Татнаркомземны да читләтеп үтеп булмый. Чөнки ул бу эш белән чынлап шөгыльләнмәде. Күп кенә МТС директорлары (Чистай, Аксубай, Юдино һ. б.) хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләүгә җавапсыз карадылар, Татнаркомзем аларга карата берниндн чара күрмәде. Без язгы чәчүгә кадәр хатын-кыз яшьләрдән 2.500 тракторчы хәзерләү эшен тәэмин итәргә тиешбез.

Комсомолның көче—партия җитәкчелегендә. Комсомол эше партия җитәкчелегеннән башка һич мөмкин түгел. ВКП(б) райкомнары менә бу большевистик принципны истә нык тотып, комсомол эшенә көндәлек җитәкчелекне көчәйтергә тиешләр.

Хезмәт ияләренең сигналларына сизгер карарга

„Красная Татария“ газетасы редакторы иптәш Анушкин реченнән

Иптәшләр! Докладчы иптәш Алемасов һәм чыгып сөйләүче делегатлар матбугат пропагандасын йомшак куйганлыгы өчен, редакциядән тыш актив белән эшләүнең җитәрлек алып барылмавы өчен, газетага кергән материалларның нәтиҗәлелеге аз булуы өчен өлкә газеталарны дөрес тәнкыйть иттеләр. Тагын да ныграк һәм күбрәк тәнкыйть итәргә кирәк иде. Чөнки өлкә газеталарның эшендә кимчелекләр күп.

Докладчы „Кызыл Татарстан“ газетасында урындагы лектор—авторларның бер лекциясе дә урнаштырылмаганлыкны әйтте. „Красная Татария“ газетасында да 2—3 кенә авторның лекциясе урнаштырылды. Бу фактлар безнең редакцияләрдә урыннардагы материалларны оештыру эше белән ныклап шөгыльләнмәгәнлекне күрсәтә.

Редакциядән тыш авторлар белән эшләү турында. Безнең партия активы, түбәнге партоешмаларның җитәкчеләре, район, шәһәр һәм өлкә комитетларының работниклары, хуҗалык һәм совет оешмаларының работниклары үзләренең өлкә газеталарында актив катнашырга тиешләр. Ләкин хәзергә кадәр „Красная Татария“га язышучы андый иптәшләр бик аз әле. Газетага иптәш Тихонов (ВКП(б) ның Киров райкомы секретаре), иптәш Суганов (Зеленодольски шәһәр комитеты секретаре), иптәш Хәкимҗанов (Минзәлә райкомы секретаре) һәм башка кайбер иптәшләр актив катнашалар. Ә безнең Татарстанда 60 тан артык район бар. Аларда һәм Казан шәһәрендә актив күп. Бездә күп кенә районнар, бигрәк тә ерак районнар, газетада кирәгенчә яктыртылмый, актив газетага бик йомшак катнаша. Безгә газетада партия оешмаларының күп төрле эшләрен яктыртырга, урындагы бай тәҗрибәләрне җыярга һәм йомгакларга кирәк. Редакция работниклары үзләре генә бу эшне башкара алмаячаклар. Безгә партия активы массасының газетага киң катнашуына ирешергә кирәк.

Газета хәбәрләренең нәтиҗәлелеге өчен көрәш мәсьәләсе турында. Безнең оешмалар газетаның һәрбер материалына сизгер карарга, күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтү һәм алдынгыларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерү чарасын күрергә тиешлеләр. Кызганычка каршы, бездә бу як җитешми әле. Безнең күп кенә оешмалар һәм җитәкчеләр газетада чыккан сигналларны күрмәмешкә салынып эндәшмичә калырга тырышалар. Биредә иптәш Черзор Наркомзем турында үзәк һәм өлкә газеталарда язылган хәбәрләр турында сөйләде. Ләкин ул аларның берсенә дә җавап бирмәде. Безнең газетада соңгы вакытта авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча Кама Тамагы, Бөгелмә һ. б. районнар турында язылды. Ләкин бу хәбәрләр буенча бер җавап та алынмады. Кайбер работниклар тәнкыйтьтән качарга, төрле сәбәпләр табып тәнкыйтьне кысарга, бюрократларча язулар белән шөгыльләнергә яраталар. Без күптән түгел генә шәһәрдәге столовойлар эшен тикшердек. Бу рейдка редакция работниклары гына түгел, бәлки җәмагатьчелек катнашты. Рейд материалы газетага чыккач, столовой һәм рестораннар тресты директоры иптәш Рафиков үзен аклау йөзеннән ике акт җибәрә. Аның актлары буенча тресттагы җитешсезлекләр өчен Рафиков түгел, бәлки җәмагать оешмалары гаепле булып чыга. Большевистик тәнкыйтькә менә мондый карашларны булдырмаска кирәк.

Хатларга караш турында берничә сүз. Безнең өлкә газеталары редакцияләренә һәр көнне йөзләрчә хатлар килә. Хезмәт ияләре төрле тәртипсезлекләрне күрсәтәләр, җидди мәсьәләләр күтәрәләр. Без аларның барсын да газетага урнаштыра алмыйбыз. Бер өлешен тиешле оешмаларга тикшерү өчен җибәрәбез. Ләкин безнең республика һәм район

оешмаларында бу хатларга сизгер караш җитәрлек түгел. Менә бер мисаль. Август аенда Чүпрәле районыннан бер хат алдык. Хатта, бер колхозның кладовщигы 10 центнер артык ашлыкны үзләштерүен ревкомиссия фаш иткәнлеге турында күрсәтелә. Без ул хатны ВКП(б) райкомына тикшерү өчен җибәрдек. Шуннан соң җавап сорап берничә тапкыр язуларга карамастан, бер нәрсә дә килгәне юк. Шундый фактлар Зеленодольски, Ютазы, Яңа Чишмә, Чаллы һ. б. районнар буенча да бар. Мондый тынычлануны бетерергә, хезмәт ияләренең хатларына сизгер карарга кирәк.

Ерактагы предприятиеләргә җитәкчелек көчәйтелсен

Бондюг заводы партбюросы секретаре иптәш Хөсәенев реченнән

Иптәшләр!

ВКП(б) Өлкә Комитетының эше турында үзенең отчет докладында иптәш Алемасов Бондюг заводының эшенә тиешенчә кагылмады. Бу завод Союз күләмендә әһәмияте булган заводларның берсе булып тора.

Мин отчет чорында заводның ничек эшләгәнлеге турында күрсәтеп үтәргә, аның эшенә кыскача характеристика бирергә уйлыйм. Бу чорда завод валовой продукция эшләп чыгаруны 44,6 процентка арттырды. Бер эшченең хезмәт җитештерүчәнлеге 46,9 процент, хезмәт хакы—44,3 процент үсте. Бу күрсәткечләр корткычлык нәтиҗәләрен бетерү, завод коллективы арасында социалистик ярышны һәм аның югары формасы—стахановчылык хәрәкәтен җәелдерү нигезендә ирешелде. Әгәр безнең завод элек производство планнарын елдан-ел үтәми һәм өзеклектән чыга алмый килгән булса, хәзер, бигрәк тә соңгы елда, ул нормаль эшли башлады. Безнең эштәге җитешсезлекләрне бетерүдә ВКП(б) Өлкә Комитетының ярдәме, әлбәттә, аз булмады. Нәтиҗәдә, 1939 нчы елны производство планы 105,2 процентка үтәлде.

Сталинчыл Өченче Бишьеллык исмендәге социалистик ярыш һәм съездның тарихи карарлары завод коллективында политик һәм производство активлыгының яңа күтәрелешен тудырдылар. Производство планын үтәүче һәм арттырып үтәүче цехлар бездә хәзер күпләп санала. Мәсәлән, начальнигы коммунист булган 11 нче номерлы цех производство планын ай саен 130—150 процент үти. 3 нче номерлы цех 1939 нчы елны еллык производство планын 5 нче декабрьгә—Сталин Конституциясе көненә 105 процент итеп үтәде.

„Красный Пролетарий“ заводы коллективының чакыруына безнең завод коллективы стахановчыларның һәм ударникларның сафларын үстерү белән җавап бирә. Хәзер безнең заводта эшләүчеләрнең 57 проценты стахановчылар һәм ударниклар. Хезмәтнең югары үрнәкләрен күрсәткән өчен югары бүләк—СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән кешеләр дә безнең коллективта бар. ВКП(б) Өлкә Комитетының безнең заводка җитәкчелеге шактый яхшырды, ләкин җитәрлек түгел әле. Булышлыкка исә безнең мохтаҗлык зур. Заводның эшендә җитешсезлекләр күп, аның эше әле канәгатьләнерлек түгел. Үткән елны производство планы 105 процент итеп үтәлүгә карамастан, 4 миллион сумлык зарар күрелде. Бу хәл бер яктан продукциянең үзенә төшкән бәясенең югары (8,9 процент) күтәрелүе белән аңлатылса, икенчедән, һәм башлыча,—район һәм республика оешмалары тарафыннан булышлыкның җитәрлек булмавы белән аңлатыла.

Завод читтән китерелә торган чималдан файдалана. Без транспорттан ерак торабыз. Бу безнең эшне кыенлаштыра, бигрәк тә кышкы шартларда. Кышын эшләп чыгарылган продукцияне без бары тик навигация вактында гына озата алабыз, чималны да шулай ук навигация вактында гына китертә алабыз. Транспорт мәсьәләсендә дә безгә зур ярдәм кирәк.

Эшләп чыгарылган продукцияне вактында озатуны һәм чималны вактында китертүне тәэмин итәргә кирәк. Моның өчен транспорт мәсьәләсе хәл кылынырга тиеш. Бондюг—Сюгинский тимер юлы төзү турында Главка, Наркомат һәм Союз хөкүмәте алдында мәсьәләне куеп, аның хәл ителүенә ирешергә кирәк. ВКП(б) Өлкә Комитетының яңа составы һәм Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы бу мәсьәлә белән якыннан торып шөгыльләнергә тиешләр.

Ә хәзер, тимер юл төзү мәсьәләсе хәл ителгәнчә, безгә өзеклектән чыгу өчен автотранспорт, автоколонна оештыруда ярдәм итәргә кирәк.

ВКП(б) Өлкә Комитетының эшенә карата монда конференциядә булган тәнкыйть дөрес. Аның эшендә җитешсезлекләр аз түгел. Кадрлар мәсьәләсен алыйк. Җитәкче эшкә яңа, яшь кадрларны күтәрү буенча отчет чорында Өлкә Комитеты зур эш башкарды. Ләкин яңа, яшь кадрларны һәр яктан хәзерләү, аларны өйрәтү мәсьәләләренә игтибар җитәрлек булмады. Башлангыч оешмаларның җитәкче работниклары өчен курслар оештырырга мөмкин иде, ләкин бу булмады. Киләчәктә бу мәсьәләгә җидди игтибар бирелергә тиеш.

Чит илләрдә

СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында АКШ матбугаты

НЬЮ-ЙОРК, 15 март. (ТАСС). „Нью-Йорк джорнэл энд Амэрикен“ газетасы, Советлар Союзы белән Финляндия арасында төзелгән солых Европада гомуми тынычлыкның ныгуы эшенә хезмәт итәр, дип яза. Һич югы, хәрби хәрәкәтләрнең бер майданы бетерелде, һәм сугышның төньякка җәелүе тукталды, ди газета. „Дейли уоркер“ газетасы Совет—Финляндия солых договоры сугышны Скандинавия илләренә җәелдерергә маташкан империалистларның планнарын җимерде, ди. Советлар Союзының кораллы көчләре, аның җиңелмәслек Кызыл Армиясе, Сталинчыл тынычлык политикасы һәм социалистик дәүләтнең [illegible] заговорларын челпәрәмә китерде.

Англия эшчеләре Совет—Финляндия солых договорын котлыйлар

ЛОНДОН, 15 март. (ТАСС). СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелүне Англия эшчеләре һәр җирдә яхшы дип табалар. Лондонның „Тынычлык өчен көраш федерациясе“нең башкарма комитеты, Совет—Финляндия солых договорыннан тирән канәгатьләнүен белдереп, үзенең барлык тарафдарларына [illegible] хәзерге империалистик сугыш майданын [illegible] чакырды. Башкарма комитет үзенең барлык членнарын көнбатышта сугышны тизрәк тәмам итү өчен кампаниягә көчәйтергә чакыра.

Кытайдагы сугыш хәрәкәтләрен күзәтү

Көньяк Кытайда соңгы вакыт эчендә японнар башлыча оборона сугышлары алып бардылар. Кытай гаскәрләренең атакалары японнарның аерым частьларын яңа килгән частьлар белән алмаштыру планнарын җимерәләр. Мәсәлән, Гуандун провинциясендә Чаочжоу—Сватоу секторына японнарның элек Цзянси провинциясендә хәрәкәт иткән [illegible]

[illegible]

ЧУНЦИН, 15 март. (ТАСС).

ФРАНКО ИТЕГЕ АСТЫНДА

Франкочылар элекке Испания республикасы территориясендә урнашкан, үз „батырлыкларының“ [illegible]

[illegible]

„Хәзерге режим буенча [illegible]

(„Известия“, 14 нче март).

СССР БЕЛӘН ИРАН АРАСЫНДА СӘҮДӘ ДОГОВОРЫ ТУРЫНДА ИРАН ГАЗЕТАСЫ

ТАҺРАН, 15 март. (ТАСС). Кичке „Иттылаат“ газетасы, Советлар Союзы белән Иран арасында яңа сәүдә договорын парафировать итү турындагы белдерүне басып чыгарып, болай дип яза: [illegible]

ТАТАРСТАННЫҢ XX ЕЛЛЫГЫНА ХӘЗЕРЛЕК

Үтәлешне тикшерәбез

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның барлык цех, бүлек һәм мастерскойларында республикабызның данлыклы XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршылау өчен зур хәзерлек алып барыла. Завод стахановчылары һәм ударниклары бу уңай белән хәзер үз өсләренә алган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерә башладылар.

Ярышып эшләү нәтиҗәсендә күп кенә бригадалар һәм аерым эшчеләр хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә үрнәк күрсәтәләр. Мәсәлән, киң куллану товарлары эшләү цехының иптәш Короткин җитәкчелек итә торган бригада заданиесен һәр вакыт арттырып үти һәм яхшы сыйфатлы продукция җитештерә.

Инструментлар цехы коллективы күп станокларда эшләү буенча яхшы нәтиҗәләргә иреште. Күп станокчы иптәш Конечин 3 станокка бирелгән заданиене 150—180 процент итеп үти. Соламин, Лавриков һәм Чугунов иптәшләр көнлек нормаларын 300—400 процентка җиткереп үтиләр.

Бу цехларның мастерлары Серин, Насыйбуллин, Гатин иптәшләр эшчеләрнең тагын да яхшырак эшләүләре өчен көрәшәләр. Аларга практик булышлык итәләр.

Соңгы вакытларда отделка цехы да яхшы эшли башлады. Бу цехта хәзер стахановчылар һәм стахановча эшләүче бригадалар саны шактый артты. *Г. Ялышев.*

Ярты еллык планны 15 нче майга үтәү өчен

Арча районының „Кызыл Масра“ промартеле стахановчылары мехчылар чакыруына җавап итеп, ярты еллык планны 15 нче майга үтәү өчен көрәшәләр. Үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә беренче квартал планы 20 нче февральдә үк 110 процент итеп үтәлде. Ә Гөберчәк авылындагы теркәү цехы (мөдире иптәш Хәнәфиев) квартал планын 200 процентка, Иске Масра авылындагы тегү цехы (мөдире иптәш Маликов) 250 процентка җиткереп үтәделәр.

Стахановчылардан Газизева Зифа, Шәрәфиева Мөкәррәмә, Сәмигуллин Вәлиулла, Сабирҗанов Һидият һәм Сабирҗанов Хәким иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Алар артельдәге яңа күтәрелешнең инициаторлары булдылар. *Н. Хәйруллин.*

Хатын-кызлар алдынгы сафта

Вахитов исемендәге жиркомбинат хатын-кызлары республикабызның данлыклы XX еллыгы исемендәге социалистик ярышта алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр.

Хатын-кызлардан квалификацияле кадрлар хәзерләү өлкәсендә аеруча зур уңышларга ирешелде. Хәзер комбинатта хатын-кызлардан 99 кеше инженер, 26 кеше мастер һәм 8 кеше аппаратчы булып эшли. 247 кеше техника укуларын уңышлы тәмамладылар. Хәзер аларның күпчелеге квалификацияле эшкә күтәрелде. Хатын-кызлар токарь, слесарь, электромонтер, аппаратчы квалификацияләрен үзләштерәләр һәм яхшы күрсәткечләр бирәләр.

Мәсәлән, шәм заводында ящик кадаклау эшендә эшләүче иптәш Ахметова норманы 150—170 процент итеп, Пуфгина, Тимофеева һәм Бариева иптәшләр 200 процент итеп үтиләр. Комбинат буенча производствода эшләүче барлык хатын-кызларның 50 проценттан артыгы үз эшләрен стахановча башкаралар. *Барый Вәлиев.*

ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕН ҮТӘДЕЛӘР

Киез итек һәм фетр фабрикасының (Казан) эшче хатын-кызларыннан 96 иптәш үзләренең укый-яза белмәүчелекләрен Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көненә бетерергә йөкләмә алганнар иде. Алар үз йөкләмәләрен намус белән үтәделәр. Укый-яза белмәүче 51 кеше аз укый-яза белүчеләр мәктәбенә күчерелде һәм 45 кеше тулы грамоталы булуга ирешге. Алар арасында фетр производствосыннан Авгалеева, Акберова, Смирнова, Орлова, тарау цехыннан Герасимова, чистарту цехыннан Галиуллина иптәшләр зурлар мәктәбен отличного тәмам иттеләр.

Укытучылардан иптәш Ушакова 43 кешене 1 нче майга һәм 50 кешене 15 нче июньгә укытып чыгарырга йөкләмә алды.

Х. Галиев.

Казанда пионерлар һәм мәктәп балалары йортының уку залында.
И. Галиев фотосы.

ЧАЙКОВСКИЙ ЮБИЛЕЕН ҮТКӘРҮ КОМИССИЯСЕНДӘ

Русның бөек композиторы П. И. Чайковский юбилеен үткәрү буенча Татарстан хөкүмәте комиссиясенең 9 нчы мартта чираттагы утырышы булды. Утырышта Татарстан Радиокомитетының һәм Татар Дәүләт Опера театрының планнары тикшерелде.

Республикабызның киң катлау хезмәт ияләрен бөек композиторның тормышы һәм иҗады белән таныштыру өчен Татарстан Радиокомитетының музыка секторы апрель аеннан башлап радио аркылы концерт-беседалар һәм лекцияләр тапшыруга керешәчәк.

Юбилей алдыннан һәм юбилей көннәрендә Татарстан Радиокомитеты, Татар Дәүләт Опера театры, музыка училищесе һәм үзешчәнлек сәнгате көчләре катнашы белән Чайковскийның өч симфониясе, опералардан өземтәләр, „Лебединое озеро“ балетыннан музыкаль монтаж һәм СССР ның Ленин орденлы Зур Драма Театрының симфоник оркестры башкаруында Чайковский музыкаларыннан тонфильм тапшырылачак. Шулай ук „Чайковский лирикасы“, „Чайковский иҗадында халык тематикасы“ һәм „Чайковский музыкаларында хор“ дигән темаларда тематик концертлар үткәрелә. Болардан тыш Чайковский иҗадына багышланып Москвадан бирелә торган концертлар транслировать ителәчәк.

Татар Дәүләт Опера театры коллективы Чайковскийның „Евгений Онегин“ операсын хәзерли һәм „Пиковая дама“, „Иоланта“ һәм башка опералардан өземтәләр өстендә эшли. Шулай ук театрның солистлары тарафыннан аерым концерт номерлары хәзерләнә.

Юбилейгә Чайковскийның тормышын һәм иҗадын чагылдырган күргәзмә төзелә.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНДА ЯҢА ПОСТАНОВКАЛАР

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры хәзерге заман совет хатын-кызының тормышын күрсәткән „Таня“ дигән пьесаны (язучысы Арбузов, тәрҗемәчесе Ильдар) куярга хәзерләнә. Пьесаны сәхнәгә театрның художество җитәкчесе Амантов куя. Пьесаның төп героинясе Таня ролен Татарстанның халык артисткасы Фатыйма Ильская башкарачак.

„Таня“ пьесасы 24 нче марттан куела башлый.

Театр коллективы шулай ук „Хуҗа Насреттин“ пьесасын да куярга хәзерли. 5 пәрдәлек бу комедия Хуҗа Насреттин турында халыкта йөри торган мотивлардан файдаланылып Нәкый Исәнбәт тарафыннан язылган. Пьесада Хуҗа Насреттин ролен артист Әбҗәлилев башкарачак. „Хуҗа Насреттин“ пьесасына композитор Җәүдәт Фәйзи тарафыннан махсус музыка язылды. Пьесаны сәхнәгә кую яшь режиссер иптәш Тумашевага тапшырылды. „Хуҗа Насреттин“ пьесасы 25 нче апрельдә куела башлый.

ТАТАРСТАНДА

— Татпромсовет системасындагы артельләрдә эшләүче кустарьларга медицина һәм культура хезмәте күрсәтү өчен узган ел 4 миллион 500 мең сум акча тотылган иде. Быел шул ук эшкә 6 миллион 800 мең сум билгеләнде.

— Быел Татарстанның Кинофикация тресты колхозларга тар пленкалы тавышлы фильмнәр күрсәтә торган 25 кино-театр ача. Шуның белән Татарстан колхозларында стационар кино-театрларның саны 65 кә тула. Автомобильләрдә йөреп тавышлы фильмнәр күрсәтү өчен яңадан 30 күчмә кино оештырыла.

— 18 нче мартта Казан Дәүләт Педагогия институтында Казан шәһәре мәктәпләренең 10 нчы класс укучылары белән очрашу кичәсе булачак. Кичәдә 1940—41 нче уку елында вузларга укучылар кабул итү һәм специальность сайлап алу турында доклад булачак. Бу кичәне чит телләр факультеты үткәрә. Шуңар күрә, художество бүлегендәге номерлар да чит телләрдә башкарылачак.

— Казанда йорт идарәләре кулындагы йортларга капитальный ремонт ясауга узган ел 761 мең сум расход тотылган иде. Быел шул ук эшләргә 1 миллион 50 мең сум билгеләнде.

Кукмара поселкысында балалар яслесе өчен (60 урынлы) яңа таш йорт салына. 240 мең сумга төшәчәк бу төзелеш Татарстан АССР ның XX еллыгына төгәлләнәчәк.

МОПР КӨНЕ АЛДЫННАН

Казанда һәм районнарда МОПР көненә хәзерлек бара. Предприятиеләрдә, колхозларда һәм совхозларда „Париж Коммунасы көне—МОПР көне“ дигән темада докладлар, беседалар үткәрелә.

Бүген, 17 нче мартта Балык Бистәсе районы үзәгендә МОПР көненә багышланган интернационал кичә оештырыла. Шулай ук бүген Казанның Яшь Тамашачылар театры художество кичәсе үткәрә. Тамашага А. Н. Островскийның „Бальзаминовның өйләнүе“ дигән пьесасы куела. Кичәдән килгән бөтен доход революция көрәшчеләренә ярдәм фондына җибәреләчәк. Мехчылар клубында да МОПР көненә багышланган кичә үткәрергә билгеләнде.

Казан Дәүләт университетының фән работниклары һәм студентлары өчен бүген университетның актовой залында тантаналы кичә ясала. Кичәдә докладтан соң үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан концерт биреләчәк.

Ш. Камал рәсме

Татар әдәбияты классигы Шәриф Камалның әдәби эшчәнлегенә 30 ел тулуны бәйрәм итү көннәренә Татгосиздат язучының зур рәсмен бастырып чыгарды.

Шәриф Камал рәсмен художник Барый Әлминев эшләгән. Рәсем 47×62 сантиметр зурлыгында эшләнеп, яхшы кәгазьгә басылган. Татгосиздат халык шагыйре Г. Тукайның, М. Гафури һәм Һ. Такташның шундый рәсемнәрен бастырып чыгарырга уйлый.

ВОДОПРОВОД ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ

Эчә торган су белән Казан шәһәре халкын тәэмин итә торган хәзерге водопровод тәүлеккә 16 мең кубометр су бирә. Бу су шәһәрдән 12 километр ераклыкта булган чишмәләрдән һәм 11 урында казылган артезиан коеларыннан алына.

Эчә торган су белән шәһәр халкын тагын да яхшырак тәэмин итү өчен хәзер Волгадан шәһәргә икенче водопровод төзү эшләре бара. Бу водопровод өчен узган ел Ершов кырыннан алып Триумфальный урамга кадәр 6.150 метр озынлыкта магистраль салынды. Быел яңадан 3.700 метр озынлыкта магистраль салыначак. Бу водопроводны салу өчен 1940 нчы елга 1 миллион 500 мең сум акча билгеләнде. Яңа водопровод тәүлеккә яңадан 40 мең кубометр су бирәчәк.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Карак-охранник. Лабзин дигән охранник „Красный Охранник“ артеленнән Мехторгның Астрономия урамындагы тегү мастерскоен сакларга җибәрелгән. Лабзин төнлә постта торган чагында мастерскойның ишегендәге пломбаны куптарып алган да, йозакны ачып кереп 4.000 сумлык мех товарлары урлаган. Мехларны озатканнан соң ул йозакны бикләгән, пломба урынына кургашын кисәге ябыштырып куйган. Милиция органнары тарафыннан чаралар күрелгәч, Лабзин кулга алынган. Урланган әйберләр Смолин дигән скорнякның квартирасында табылган. Бу эш буенча гаепләнеп, 4 кеше суд җаваплылыгына тартыла.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН КИНОПЛЕНКА ТЕХНИКУМЫ
техникумга хәзерлек буенча 3 айлык кичке курсларга
УКУЧЫЛАР АЛА
КУРСЛАРГА 16 ДАН 30 ГА КАДӘР ЯШТӘГЕ БУЛГАН ҺӘМ УРТА МӘКТӘПНЕҢ КИМЕНДӘ 7 КЛАССЫ КҮЛӘМЕНДӘ БЕЛЕМЛЕ КЕШЕЛӘР АЛЫНАЛАР
Гаризалар шушы ел 23 нче мартка кадәр алына. Укулар шушы ел 25 нче марттан башлана.
Техникумга хәзерлек курсларына керү турында гаризалар техникум директоры исеменә бирелә.
Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, белеме һәм яше турында документлар, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе һәм хезмәте урыныннан белешмә бирелергә тиеш. Болардан тыш паспорт күрсәтелә.
Курсантларга тору урны һәм уку кирәк-яраклары бирелми.
Техникум биш белгечлек буенча: целлюлоза эфирлары эшләү, фотожелатин эшләү, кинопленка аслыклары һәм фотографик катлаулар эшләү, шулай ук кино-фото материаллары эшкәртү белгечлекләре буенча техник-технологлар хәзерли.
Техникумны тәгәлләүчеләр күрсәтелгән белгечлекләр буенча Казанда, Москвада, Ленинградта, Киевта, Тбилисида һәм башка шәһәрләрдә эшкә урнаштырылалар.
Техникумда уку срогы 4 ел. Техникумда укулар производстводан аерылып алып барыла. Казан, Кинопленка техникумы. Телефон: Кинопленка комутаторы, 1—49. Белешмәләр алу һәм гаризалар бирү өчен һәр көн иртән 9 сәгаттән көндез 4 кә кадәр мөраҗәгать итәргә.
473—2—1

СССР Наркомхимпромының 1940 нчы ел 26 нчы февральдә чыгарган 93 нче һәм агач материаллары хәзерләү буенча бөтенсоюз тресты „Химзаготлес“ ның 1940 нчы ел 24 нчы февральдә чыгарган 57 нче номерлы приказлары нигезендә,
„Химзаготлес“ трестының агач материаллары хәзерләү буенча Казан өлкәара конторасы шушы ел 1 нче марттан эшен туктатты.
Контогага буйсынган хуҗалык исәбендәге предприятиеләр турыдан-туры „Химзаготлес“ тресты карамагына күчерелделәр.
„Химзаготлес“ ның Казан конторасына карата булган дәгъвалар шушы ел 25 нче мартка кадәр алына. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62.
484—1

19 нчы март, кич 7 сәгатьтә Тире-Венера Авырулары клиникасы аудиториясендә Казан Дәүләт Мединституты гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм медицина фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен түбәндәге темаларда
ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә:
1. Врач Г. З. Мөхәмәдьяров. Тема: „Шварцман феномены һәм йорт куяннарында сифилис“.
Рәсми оппонентлар: профессор А. Д. Адо, һәм профессор И. Н. Олесов.
2. Врач А. И. Чигарин. Тема: „Йөклелек токсикозалары вактында актив мезенхиманың функциональ хәле турында“.
Рәсми оппонентлар: профессор П. В. Маненков һәм доцент Н. Н. Вылегжанин.
Диссертация материаллары белән Фәнни Медицина Җәмгыятьләре китапханәсендә танышырга мөмкин.
488—1

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
17 нче мартка билгеләнгән спектакль булмый.
18 нче мартта
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми.

КИРӘК:
„Культпром артеленә даими эшкә, АГАЧ ЭШЛӘҮ БУЕНЧА ТОКАРЬЛАР ҺӘМ СЛЕСАРЬЛАР. Казан. Нариманов урамы, 93.
489—1

„Гужтранс-Заречье“ артеленә даими эшкә СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, ХИСАПЧЫ һәм КАРТОТЕКАЧЫ. Ягодный бистәсе, Краснококшай урамы, 85. Телефон 26—33.
491—2—1

Фото-Желатин заводы төзелешенә, монтаж һәм эксплоатация буенча эшләү өчен 6—7 нче РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР. Тору урны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-Желатин заводының кадрлар бүлеге.
474—5—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген кич һәм иртәгә көндез
ПАВЕЛ ГРЕКОВ
18 нче мартта кич
КУРКЫНЫЧЛЫ БОРЫЛЫШ
Талоннар белән кертелми.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 17 нче мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хәйван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
18 нче мартта зур программада
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 5-30, 7, 8-30, 30 да.	Тавышлы, яңа кино-комедия ТАШЛАНДЫК
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ПРИДАНСЫЗ КЫЗ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ПАТРИОТ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ЯШӘРГӘ